**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

13.11.2010 № 9686/10
На № ______________ ____________________

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары башкарма
комитетларының мәгариф идарәләре
һәм бүлекләре җитәкчеләренә

Муса Җәлил исемендәге I республикакүләм
фәнни-гамәли конференция нигезләмәсен
җибәрү турында

2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру, патриот шагыйрь, Советлар Союзы герое Муса Җәлилнең тууына 105 ел тулу уңаеннан иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау максатыннан, 2011 нче елның 14 нче февралендә Балтач муниципаль районы Карадуган урта гомуми белем мәктәбе базасында Муса Җәлил исемендәге I республикакүләм фәнни-гамәли конференция үткәрелә.

Халкыбызның милли үзенчәлекләре, күркәм сыйфатлары, аның батыр уллары үрнәгендә укучыларны тәрбияләүдә, буыннар бәйләнешен тәэмин итүдә әһәмиятле чара булуын исәпкә алып конференциядә катнашырга тәкъдим итәбез.

Конференциянең нигезләмәсе теркәлә.
Кушымта: 3 биттә.

Министрның беренче урынбасары Д.М. Мостафин

Г.Г.Әхмәдуллина
292-27-74

**Муса Җәлил исемендәге I республикакүләм фәнни-гамәли конференциянең нигезләмәсе**

Республикакүләм фәнни-гамәли конференция патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 105 ел тулу уңаеннан иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау, 2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

**Максаты һәм бурычлары:**

- Муса Җәлилнең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау;
- укучыларда фәнни-тикшеренү күнекмәләре формалаштыру;
- бүгенге көн укучысының әхлак, әдәп идеалларын билгеләү;
- халкыбызның милли үзенчәлекләре, күркәм сыйфатлары, аның батыр уллары турында сөйләп, укучыларны өлкәннәр үрнәгендә тәрбияләү, буыннар бәйләнешен тәэмин итү;
- гомумкешелек кыйммәтенә аңлы караш тәрбияләү;
- фәнни эзләнүләрдә иҗадилыкка омтылышларын булдыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру.

**Катнашучылар**

конференция эшчәнлегендә гомуми белем учреждениеләренең 8-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

**Конференцияне үткәрү шартлары һәм тәртибе**

Конференция 2011 нче елның 14 нче февралендә Балтач муниципаль районы Карадуган урта гомуми белем мәктәбендә үткәрелә.

Укучы үзе сайлаган темага чыгыш әзерли (эзләнү эше, реферат, доклад, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал булырга мөмкин).

*Эшләр түбәндәге юнәлешләрдә дә булырга мөмкин*

1. Татар әдәбияты, тарих (эзләнү эшләре, әдәбиятта Бөек Ватан сугышының чагылышы).
2. Батырларны барлап (Бөек Җиңүнең 65 еллыгы уңаеннан).
3. Җәлил премиясе лауреатлары турында эзләнү эшләре (җирле материалларга нигезләнгән булуы шарт).
4. Батырлар эзе буйлап (Җәлил һәм аның көрәштәшләре).

Хезмәтләр татар һәм рус телләрендә була ала.
Текстның күләме 8 басма биттән артмаска тиеш.

Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр булырга мөмкин).

**Хезмәтнең язылу тәртибе**

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times Roman-14, интервал 1,5, уңнан – 1,5, сулдан -2,5, астан – 2, өстән – 1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, районы, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешенең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

*Эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:*

- укучының теманы ачып бирә алуы, композициянең тулылыгы;
- дәлилле һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы;
- эшнең грамоталы, әдәби телдә язылган, китерелгән фактларның дөрес булуы шарт.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты 3-5 минут.

Укучы шушы вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен әйтеп бирә белергә тиеш (компьютер презентациясе хуплана).

Эшләр (электрон һәм язмача вариантта) заявка белән бергә 2011 нче елның 10 нчы гыйнварына кадәр мәгълүмати-методик үзәккә (422250, Балтач муниципаль районы, Балтач п., Мәктәп урамы, 2 а) җибәрелә.

Уңышлы дип табылган эш авторларына аерым чакыру җибәреләчәк.

| № п.п | Ф.И. әтисенең исеме, туган елы | Район, мәктәп №, класс | Адрес, индекс | Паспорты буенча мәгълүмат: кем тарафыннан, кайчан бирелгән | ИНН һәм пенсия, иминият таныклыгы | Фәнни җитәкченең Ф.И. әтисенең исеме. | Элемтә өчен телефон номеры (районның коды) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**Конференцияне оештыручылар**

1. Балтач районы башкарма комитеты.
2. Балтач районы мәгариф бүлеге.
3. Балтач районы мәгълүмати-методик үзәк.
4. Карадуган «Себер тракты тарихы» музее.
5. Карадуган урта гомуми белем мәктәбе.

## Чыгышларны бәяләү өчен критерийлар

- эшнең фәннилеге;
- заман таләпләренә туры килүе;
- шул тема өстендә эшләүче галимнәрнең фикеренә таяну;
- эшләрнең җирле материалларга нигезләнгән булуы;
- эшнең максатын дөрес билгеләү;
- логик яктан дөрес фикерләү, дәлилләнгән нәтиҗәләр ясау;

## Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиянең карары турында беркетмә языла.

Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр һәм дипломнар тапшырыла.

Белешмәләр өчен телефоннар:
Мәгълүмати-методик үзәк: 8(84368) 2-52-32
Карадуган урта гомуми белем мәктәбе: 8 (84368) 32119